**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 7 июлендәге 2359 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 октябрендәге 3397 номерлы**
**«“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 31 декабрендәге 1044 номерлы «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт биреме формалаштыру һәм дәүләт биреме үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 9 октябрендәге 3397 номерлы «“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбулада, карарга кушымтаның 1.1, 1.4 пунктларында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 сентябрендәге 759 номерлы “2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативын раслау турында”гы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 сентябрендәге 685 номерлы “2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның план чорына алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын

оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативын раслау турында”гы карары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның 2 пунктында «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**